| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЧЕРЕМШАНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>СОВЕТ ЛАШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br><br>ул.Советская дом 55А, село Лашманка,<br>423110 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЛАШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br><br>Советлар урамы,55Айорт, Лашман авылы,<br>423110 |
|---|---|---|

тел./факс +7(84396) 2-92-35 email: Lash.Cmn2@tatar.ru

№ 128 07.11.2024 ел.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Лашман авыл җирлеге Советы**
**карары**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

- мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү (скважиналар, су җыю манаралары, суүткәргеч челтәрләр), шул исәптән муниципаль милектәге һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү, муниципаль милектәге мөлкәт, җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм контрольдә тоту, шул исәптән:

а) муниципаль милектәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү буенча, муниципаль мөлкәтне оператив идарә итү (хуҗалык алып бару) хокукында муниципаль учреждениеләргә (предприятиеләргә) беркетү турында; тартып алу, сату турында; аренда түләве күләмен билгеләү, үзгәртү турында; арендага бирү турында (шул исәптән муниципаль преференцияләр бирү турында); мөлкәтне файдалануга тапшыру турында; Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә мөлкәт белән идарә итүгә һәм эш итүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча милеккә бирү, шул исәптән судларда, контроль (күзәтчелек) органнарында «Җирлек» мәнфәгатьләрен яклау турында хокукый актлар чыгару (кабул итү);

б) муниципаль мөлкәткә карата Россия Федерациясе законнары нигезендә граждан-хокукый шартнамәләр төзү, шул исәптән аларны хокукый анализлауны һәм килештерүне, шулай ук шартнамәләр шартлары буенча фикер каршылыкларын җайга салу максатларында контрагентлар белән хат алышуны тәэмин итү;

в) мөлкәткә карата шартнамәләр буенча алынган акчаларны җирлек бюджетына күчерү;

г) муниципаль мөлкәтне федераль милеккә, Татарстан Республикасы милкенә, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче башка муниципаль берәмлекләр милкенә тапшыру;

д) муниципаль милек объектларын хосусыйлаштыру документларын саклау;

е) муниципаль мөлкәтне сату, арендага бирү, файдалану, идарә итү буенча гамәлдәге законнар нигезендә аукционнар һәм конкурслар оештыру.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына: 2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге Советының 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Лашман авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе : Р.Г.Фәттахов